РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«19» ноябрь 2024 ел г. Альметьевск № 3680

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль
районы Башкарма комитетының «Элек
хосусыйлаштырылган торак урыннарны
муниципаль милеккә кабул итү буенча
муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ
регламентын раслау турында» 2022 елның
28 февралендәге 315 номерлы карарына
үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль законнар, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә

БАШКАРМА КОМИТЕТ КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «Элек хосусыйлаштырылган торак урыннарны муниципаль милеккә кабул итү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2022 елның 28 февралендәге 315 номерлы карарына (Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 2 ноябрендәге 2543 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

карарның 1 нче кушымтасында:

1.3.2 пунктының 2) пунктчасында, 2.5.1 пунктының 1) һәм 3) пунктчаларында, 2.5.2 пунктының 2) пунктчасында, 2.5.3 пунктында, 2.7.1 пунктының 5) пунктчасында, 2.13.2 пунктында, 2.15.2 пунктының 9) абзацында, 2.16.1 пунктының 2) һәм 6) пунктчаларында, 2.16.2 пунктында, 2.16.3 пунктының 5) пунктчасында, 2.16.4 пунктының 1) һәм 4) абзацларында, 3.2.3 пунктының 1 абзацында, 3.3.2 пунктында, 3.7.3.2 пунктларының 1) һәм 3) абзацларында, 3.8.1 пунктының 5 абзацында тиешле санда һәм килештә «Республика порталы» сүзләрен тиешле санда һәм килештә «Бердәм, республика порталы» сүзләренә алмаштырырга;

3.3.2.1 пунктының 11 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Төзелгән гарызнамәне формат-логик тикшерү орган (оешма) билгеле торган

таләпләр нигезендә, мөрәҗәгать итүче гарызнамәнең электрон рәвешендәге һәр кырын тутырган вакытта, бердәм портал тарафыннан автомат рәвештә гамәлгә ашырыла. Бердәм портал сорауның электрон рәвешендәге дөрес тутырылмаган кырын ачыклаганда, мөрәҗәгать итүчегә ачыкланган хатаның характеры һәм аны бетерү тәртибе турында турыдан-туры сорауның электрон рәвешендәге мәгълүмати хәбәр аша хәбәр ителә».

карарга 3 нче кушымтада «□Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталының шәхси кабинетына» сүзләреннән соң өстәргә:

«□Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталының шәхси кабинетына».

2. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад буенча урынбасары А.Ә. Ямалетдиновка йөкләргә.

Район Башкарма комитеты
җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы А. М. Каюмов